Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

2022 елның 11 ноябре № 41

Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Киндер Күл авылы, Клуб урамы, 20 б адресы буенча мәчет бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 25 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Киндер Күл авылы, Клуб урамы, 20 б адресы буенча мәчет бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Киндеркүл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Киндер Күл авылы зиратын коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Киндер Күл авылында урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Киндер Күл авылында урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Киндер Күл авылы территориясен төзекләндерү;
- Киндер Күл авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза үткәрү.
- Насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Киндер Күл авылы юлларына вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп, чокырларны ремонтлау, торбалар сатып алу һәм салу; (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Киндер Күл авылына янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, янгын гидрантларын комплектлау, смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Киндер Күл авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау (торбаларны алыштыру, материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хәбибуллина